ЧӘРШӘМБЕ
17
МАРТ
1943 ел.
№ 61 (6783)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Иптәш Сталинның котлавына безнең җавап

Кызыл Йолдыз районы колхозчылары Такрановларның һәм Бикташеваның хаты

Иптәш Сталинның Татарстан хезмәт иярәренә җибәргән котлау телеграммасын без гаять зур шатлык белән укыдык. Бөек юлбашчының, атабызның, остазыбызның һәм совет халкы дустының котлау сүзләре безнең һәркайсыбызга юнәлдерелгән. Алар тагын да яхшырак эшләүгә, фронт өчен, туган Кызыл Армиябез өчен тагын да күбрәк тырышлык күрсәтергә рухландыралар.

Без, Кызыл йолдыз районы колхозчылары сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинның котлавын укыгач, үз-үзебездән:—Без ана нәрсә белән җавап бирербез? Кабахәт немец фашистларны тизрәк тар-мар итәргә без үзебезнең данлыклы сугышчыларыбызга ярдәм күрсәтү өчен нәрсә эшләрбез? — дип сорадык.

Һәм безнең һәркайсыбыз карар бирде: Кызыл Армияне һәм илне азык белән тәэмин итү өчен, героик совет гаскәрләре гитлерчыларның коллыгыннан азат итә торган туганнарыбызга ярдәм күрсәтү өчен, быел ничек кенә булса да югары иген уңышы алырга кирәк. Әгәр дә кайбер артельләрдә чәчүлек орлык җитмәсә, кырларны тулысынча чәчәргә ярдәм күрсәтү, моның өчен үзеңнең запасларыңнан бурычка ашлык биреп тору—һәрбер колхозчының изге бурычы.

Без шулай карар бирдек һәм шулай эшләдек. Мин, «Восход» авыл хуҗалыгы артеленнән Петр Такранов, үз колхозыбызның кырларына чәчү өчен 61 пот ашлык һәм 48 пот бәрәңге бирәм. Мин, шул ук артельдән Егор Такранов, 24 пот ашлык һәм 24 пот бәрәңге бирәм. Мин, «Авангард» колхозыннан Анастасия Бикташева, 51 пот ашлык бирәм.

Татарстанның барлык клюхозчыларын һәм колхозчы хатын-кызларын үзебездән үрнәк алырга чакырабыз.

«Восход» артеле колхозчылары — **П. Такранов, Е. Такранов.**

«Авангард» артеле колхозчысы—**А. Бикташева.**

КОЛХОЗЧЫЛАРНЫҢ ЯҢА ПАТРИОТИК ЭШЛӘРЕ

Фронт белән тылның көчле һәм бердәм ударларын дошман инде берничә кат татыды. Миллионнарча фрицлар үзләренә кабер таптылар. Дошман, әлбәттә, юк ителергә тиеш һәм юк ителәр! Моңа совет кешеләренең ышанычы зур. Ләкин шул ук вакытта үз-үзеңне тынычландыру, гамьсезлек совет кешеләре өчен чит нәрсә. Әле фронт геройларыннан, тыл кешеләреннән күп көч, күп энергия таләп ителә. Дошманның көче бөтеп җитмәгән әле. Аның төрле авантюраларга баруы мөмкин. Бу хәл безнең сугышчыларыбызга, фронтка ярдәмне торган саен арттыра баруны таләп итә. Совет патриотлары:

— Фронтка һәртөрле ярдәмебезне көчәйтик!—диләр һәм совет кешеләре аны тагын да зуррак булган энергия белән күтәреп алалар, бөтен халыкның патриотик хәрәкәтенә әйләндерәләр. Колхозчы Ферапонт Головатый илебезнең барлык колозчыларына: «Танклар колоннасы төзик!» дип мөрәҗәгать итте. Шуннан соң, илебезнең барлык колозчылары танклар колоннасы төзелешенә акча туплый башладылар. Бу һәркемгә билгеле: ул куәтле, патриотик хәрәкәт булып әверелде. Безнең республикабыз буенча гына да танклар колоннасы төзелешенә 100 миллион сум акча туплау моны ачык күрсәтә. Самолетлар эскадрильялары төзелешенә средство туплау да шундый ук гаять зур патриотик күтәренкелек белән үтте. Республикабызның барлык колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына, барлык хезмәт ияләренә бөек юлбашчыбыз ике тапкыр котлау телеграммасы җибәрде һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырды.

Советлар Союзы Маршалы; сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинның котлавы республикабыз колхозчылары арасында, эшчеләр, инженер-техник работниклар арасында, совет интеллигенциясе арасында гаять зур политик һәм производство активлыгы тудырды.

Газетабызның бүгенге номерында Кызыл йолдыз районының колхозчылары Петр Такранов, Егор Такранов һәм Анастасия Бикташева иптәшләрнең хаты урнаштырыла. «Восход» авыл хуҗалыгы артеле колхозчысы иптәш П. Такранов үз колхозына үз запасыннан 61 пот ашлык, 48 пот бәрәңге, шул ук артельдән иптәш Е. Такранов 24 пот ашлык, 24 пот бәрәңге, «Авангард» колхозыннан иптәш А. Бикташева 51 пот ашлык биреп торырга булганнар. Алар республикабызның барлык колхозчыларын да үзләреннән үрнәк алырга чакыралар. Бу гаять зур патриотик эш! Бу, безнең колхозчы крестьяннарыбызның үз колхозлары турында тирән кайгыртучанлык күрсәтүләре турында, безнең сөекле Кызыл Армиябезне, илебезне икмәк белән тулысынча тәэмин итү өчен көрәшүләре турында ачык сөйли.

Кызыл йолдыз районының башка колхозларында да бу хәрәкәт көннән-көн җәелә бара. Хәзер инде район буенча колхозчылардан үз колхозларына ярдәм тәртибендә 4.248 пот бөртекле ашлык, 37 мең поттан артык бәрәңге орлыгы, 2 центнер кәбестә орлыгы, 2 центнер 42 килограмм суган орлыгы һ. б. кергән. Бу хәрәкәт Беренче Май районында да киң җәелә. Хәзер колхозчылардан үз колхозларына ярдәм тәртибендә 755 центнер бөртекле культуралар орлыгы, 1.380 центнер бәрәңге орлыгы, 33 килограмм яшелчә орлыгы кертелгән. Бу өлкәдә кайбер колхозчылар аеруча зур активлык күрсәтәләр.

Язгы чәчү инде көннән-көн якынлаша. Аңа барлык тармаклар буенча да эшлекле һәм актив әзерләнгән хәлдә, орлык туплау мәсьәләсенә аеруча игътибар бирелергә тиеш. Чәчүгә әзерлектә орлык—ул, төп мәсьәлә. Моны бер генә минутка да онытырга ярамый. Алдынгы колхозчыларның үз колхозларына орлык белән ярдәм итүдәге яхшы башлангычына киң юл бирелсен! Партия, совет оешмаларының, җир органнарының бурычы, иптәш Сталинның котлау телеграммасы үңае белән колхозчылар арасында туган политик һәм производство активлыгына дөрес юнәлеш бирүдән, Кызыл йолдыз районының алдынгы колхозчылары чакыруын барлык колхозчыларга җиткерүдән гыйбарәт.

Һич шик юк: республикабызның барлык колхозчылары да Петр һәм Егор Такрановларның, Анастасия Бикташеваның патриотик чакыруларына кушылырлар һәм үз колхозларына чәчүлек орлык белән ярдәм итүдә зур активлык күрсәтерләр һәм хәрби уңыш алуны тәэмин итү өчен бөтен энергияләрен биреп эшләрләр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

16 нчы МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

16 нчы мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Вязьмадан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә дистә пунктны алдылар. Н-че часть халык яши торган бер зур пункт өчен барган бик каты сугышта немецларның 300 гә якын солдат һәм офицерларын кырып ташлады. Дошманның бу терәк пунктын алганнан соң, безнең сугышчылар немецларның 4 танкысын, 5 орудиесен һәм бер сугыш припаслары складын кулга төшерделәр. Вязьмадан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар, дошманның бик нык каршылык күрсәтүен җиңеп, алга бардылар.

* * *

Төньяк Донецның урта агымы районында безнең частьлар бик каты сугышларда немецларның 32 танкысын, 15 орудиесен һәм дошман пехотасы төялгән 40 автомашинасын юк иттеләр. Халык яши торган бер зур пункт районында гитлерчылар су чиге аркылы үтеп чыгарга маташканнар иде. Безнең подразделениеләр дошманның атакасын кире кайтардылар һәм немецларның бер ротага якын пехотасын кырып ташладылар. Безнең мина кырына бәрелеп, немецларның бер самоход пушкасы һәм 2 авыр танкысы җимерелде.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманга каршы ут сугышы алып бардылар. Артиллеристлар һәм минометчиклар дошманның 6 ДЗОТ ын җимерделәр һәм 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар. Икенче бер участокта Н-че часть разведчиклары дошманның тылына үтеп керделәр һәм берничә урында тимер юлны шартлаттылар.

* * *

Ильмень күленнән көньяктарак Н-че часть сугышчылары, кичә дошман оборонасының үзелын алып, ике танк, 2 орудие һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр һәм дошманның бер зенит батареясын, 15 пулеметын, 100 дән артык винтовкасын һәм бер сугыш припаслары складын кулга төшерделәр. Төнге сугышта 200 дән артык гитлерчы юк ителде.

* * *

Киев өлкәсе районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче бер партизаннар отряды бер ай эчендә немецлар кулындагы тимер юл станцияләренә берничә тапкыр һөҗүм ясаган. Совет патриотлары 200 гә якын гитлерчыны кырып ташлаганнар һәм немецларның кораллар, сугыш припаслары һәм азык төялгән 7 эшелонын юлдан чыгарып аударганнар. 7 паровоз һәм 140 вагон юк ителгән. Партизаннар дошманнан 4 пулемет, 164 винтовка, 13 пистолет, 13.600 патрон һәм немецларның крестьяннардан талап алган 2 склад ашлыгын кулга төшергәннәр. Партизаннар ашлыкны халыкка өләшкәннәр.

* * *

Күптән түгел Минск өлкәсенең Поликарповка авылына немецларның бер җәза отряды килгән. Гитлерчыларның авылны яндырырга һәм барлык халыкны кырып бетерергә теләгәнлекләре турында крестьяннарга алдан ук хәбәр ителгән булган. Крестьяннар үзләренең тормышларын көрәшсез корбан итмәскә карар биргәннәр. Барлык ирләр, хатын-кызлар һәм яшь үсмерләр, балталар һәм сәнәкләр тотып, колхозчы Ахрем Васильевич Марков җитәкчелегендә, немец бандитларга һөҗүм иткәннәр. Фашистик карательләргә каршы коралсыз, ләкин батыр совет патриотларының көрәше берничә сәгать дәвам иткән. Тигезсез сугышта Поликарповка авылының крестьяннары һәм крестьян хатын-кызлары 20 гитлерчыны кырып ташлаганнар. Күп кенә крестьяннар батырлар үлеме белән үлгәннәр, ә калганнары партизаннарга киткәннәр.

16 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

16 нчы мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

15 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 150 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар. 20 артиллерия һәм миномет батареясының утын бастырдылар, бер тимер юл эшелонын җимерделәр, бер батальонга якын пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Көнбатыш фронт гаскәрләре, дошманның көчле ут каршылыгын һәм контратакаларын җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Холм-Жирковскийны алган чакта безнең частьлар дошманның 52 танкысын, 19 орудиесен, 60 пулеметын, 18 минометын, 10.000 снарядын һәм 50.000 патронын кулга төшерделәр. Дошманның үтерелгән солдат һәм офицерлары гына да 1.000 гә җитте.

* * *

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган 32 пунктны алдылар. Н-че часть подразделениеләре, дошманны көчле итеп ныгытылган халык яши торган бер пункттан бәреп чыгардылар һәм немецларның 3 танкысын, 20.000 патронын 1 телефон кабеле складын һәм башка төрле сугыш милекләрен кулга төшерделәр. Бу терәк пунктыннан чигенгән чакта немецлар ике яклап булган пулемет уты астына килеп эләктеләр һәм үз солдатларының һәм офицерларының 300 гә якын үле гәүдәләрен калдырдылар.

* * *

Төньяк Донецның урта агымы районында безнең танкистлар дошман танкларының һәм мотопехотасының зур колоннасына атака ясадылар. Танк сугышы нәтиҗәсендә немецлар үзләре өчен зур югалтулар белән алып ташландылар. Икенче бер участокта безнең частьлар дошманның берничә атакасын кире кайтардылар һәм немецларның 5 танкысын, сугыш припаслары төялгән 6 автомашинасын һәм 10 повозкасын юк иттеләр. Артиллерия уты белән гитлерчыларның сугышлар бара торган урынга килеп җиткән бер батальоны таркатылды.

* * *

Ильмень күленнән көньяктарак Н-че берләшмә частьлары бер урманны дошманнан чистарттылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Гитлерчылар каты каршылык күрсәтәләр, ләкин совет сугышчыларының басымы астында чигенергә мәҗбүр булалар. Бер тар участокта гына да 200 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

Һава сугышларында һәм зенит артиллериясе уты белән немецларның 18 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның ике гарнизонына һөҗүм иткән. Партизаннар 130 дошман солдатын һәм офицерын кырып ташлаганнар һәм бер полиция идарәсен туздырганнар. Орел партизаннарының икенче бер отряды немец-фашист оккупантларның 2 орудиесен, 6 минометын, 14 пулеметын, 125 винтовкасын, 89.000 патронын, 3 азык складын һәм бик күп төрле башка сугыш милекләрен кулга төшергәннәр. Партизаннар 80 гитлерчыны плен алганнар.

* * *

Түбәндә Курск өлкәсенең Желудки авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немец-фашист ерткычлар хуҗа булып торган вакыт эчендә авылны бөтенләй таладылар. Немецлар күп кешеләрне ирексезләп Германиягә алып киттеләр. По-

(Ахыры 4 нче биттә).

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләү турында

(АХЫРЫ)

Халыкара коммунистик хатын-кызлар көне — 8 нче мартны истә калдыру теләге белән промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларыннан түбәндәгеләрне Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамоталары белән бүләкләргә:

274. Мария Михайловна **Филонычеваны**—Столбище МТС ы тракторчысы.

275. Александра Максимовна **Фрюлованы**—Столбище районы, «Красный Октябрь» колхозының умартачысы.

276. Фатиха Хәбибулла кызы **Хәбибуллинаны** — Н-че завод эшчесе.

277. Мәфтуха **Хәйретдинованы** — Апас районы, «Кызылармеец» колхозының көтүчесе.

278. Разия **Хәйруллинаны** — Н-че завод слесаре.

279. Сәлимә Хәйрулла кызы **Хәйруллинаны**—Азнакай районы, Сапай тулы булмаган урта мәктәбе укытучысы.

280. Әминә **Хәйретдинованы**—Кама Тамагы районы, Олы Келәре МТС ы тракторчысы.

281. Зәйтүнә **Хәйретдинованы**—Н-че завод эшчесе.

282. Шәмсекамәр Хәйретдин кызы **Хәйретдинованы**—Н-че завод эшчесе.

283. Мәгъсума **Халикованы**—Буа районы, «Лена» колхозы председателе.

284. Фатима **Хәлиуллинаны** — врачларның белемнәрен күтәрү институтының санитаркасы.

285. Суфия Вәлиулла кызы **Хәмидуллинаны** — эвакогоспиталь медсестрасы.

286. Фанилә Халик кызы **Хатыйпованы**—Казан киез итек-фетр фабрикасының смена мастеры.

287. Нәфисә Хафиз кызы **Хафизованы**—3 нче номерлы механикалаштырылган пекарняның смена начальнигы.

288. Нәҗия **Хисамованы**—Чүпрәле районы, «Йолдыз» колхозының звено башлыгы.

289. Мария Дмитриевна **Храмованы** — Столбище МТС ының трактор бригадасы бригадиры.

290. Мәрьям Гафиятулла кызы **Хөснетдинованы** —Н-че завод эшчесе.

291. Нина Степановна **Черняеваны**—Казан станциясе вокзалының аналар һәм балалар бүлмәсе начальнигы.

292. Татьяна Андреевна **Черепованы** — Мамадыш районы, элемтә конторасының телеграфисткасы.

293. Наталья Андреевна **Чижованы**—Казан Почтаматының почтальоны.

294. Халифә **Шабаеваны** — Н-че завод эшчесе.

295. Рабига Фәйзерахман кызы **Шакированы**—«Светоч» фабрикасы директоры:

296. Разия Вильдан кызы **Шакированы**—Н-че завод эшчесе.

297. Суфия Шакир кызы **Шакированы**—Таткоопиносоюзның «Казинторг» артеле эшчесе.

298. Хәбирә **Шакированы**—Н-че завод эшчесе.

299. Гөлчирә **Шәрәфиеваны**—Апас районы, Чүрибураш МТС ы тракторчысы.

300. Асия Исмәгыйль кызы **Шәрипованы**—эвакогоспиталь санитаркасы:

301. Александра Федоровна **Шашаринаны**—Чаллы районы, «Нива» колхозының звено башлыгы.

302. Разия **Шиһапованы**—Н-че завод эшчесе.

303. Ефросинья Николаевна **Шипкованы**—Металлпромсоюзның «Прогресс» артеле эшчесе.

304. Мария Григорьевна **Шиляеваны** — Н-че заводның ВЛКСМ комитеты секретаре.

305. Александра Степановна **Шклеваны**—В. И. Ульянов (Ленин) исемендәге Казан университетының чит ил телләре кафедрасы мөдире.

306. Фрина Ароновна **Юдкевичны** — Казан ит комбинатының казылык цехы начальнигы.

307. Менарет Борһан кызы **Юскаеваны**—ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре.

308. Мәргуп Ибраһим кызы **Юсупованы**—хезмәт ияләре депутатларының Бауман район советы башкарма комитеты председателенең урынбасары.

309. Рәкыя Йосыф кызы **Юсупованы**—Добьяз районы, «Кызыл юл» колхозының ат караучысы.

310. Александра Васильевна **Яковлеваны**—Казан пристаненың «Катунь» баржасы шкиперының ярдәмчесе.

311. Валентина Алексеевна **Яковлеваны** Н-че заводның өлкән контроль мастеры.

312. Пелагея Яковлевна **Яковлеваны**—Түбән Ослан затоны пычкычысы.

313. Анна Григорьевна **Якубовскаяны**—Н-че заводның 6 нчы номерлы цех бригадиры.

314. Кәшифә **Яруллинаны**—Казан тимер юлының путевой обходчигы.

315. Нургаян Насыйбулла кызы **Яруллинаны**—Казан пристане грузчигы.

316. Александра Леонидовна **Ясницкаяны**—Казан авыл хуҗалыгы институтының микробиология кафедрасы ассистенты.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе
Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы секретаре хезмәтләрен үтәүче Г. ШӘМСИЕВА.

Казан, Кремль. 9 март, 1943 ел.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

КОЛХОЗЧЫ ИПТӘШЛӘР! ҮЗ КОЛХОЗЫГЫЗГА ТАКРАНОВЛАРЧА БУЛЫШЛЫК ИТЕГЕЗ!

Колхозларның ОРЛЫК ФОНДЫНА

СОВЕТ ПАТРИОТЛАРЫНЫҢ ВЗНОСЫ

1. Кызыл йолдыз районының «Восход» колхозы члены П. ТАКРАНОВ 61 пот бөртекле ашлык һәм 48 пот бәрәңге бирде.

2. Кызыл йолдыз районының «Авангард» колхозы члены А. БИКТАШЕВА 51 пот бөртекле ашлык бирде.

3. Кызыл йолдыз районының «Восход» колхозы члены Е. ТАКРАНОВ 24 пот бөртекле ашлык һәм 24 пот бәрәңге бирде.

4. Кызыл йолдыз районының «Таң» колхозы председателе А. ГЫЙЛАҖЕТДИНОВ 24 пот бөртекле ашлык һәм 24 пот бәрәңге бирде.

5. Кызыл йолдыз районының Югары Сөн авыл советы председателе М. ЮСУПОВ 24 пот бөртекле ашлык һәм 24 пот бәрәңге бирде.

6. Кызыл йолдыз районының «Таң» колхозы члены иптәш Г. БАТЫРШИН 18 пот бөртекле ашлык һәм 18 пот бәрәңге бирде.

7. Теләче районының, «Кече Кибәхуҗа» колхозы председателе Г. ХАЛИУЛЛИН 24 пот бөртекле ашлык бирде.

Колхозчыларда активлык үсә

ЮГАРЫ ОСЛАН, 13 март. (Телефон буенча). «13 лет октября» авыл хуҗалыгы артеле членнары Кызыл Армиягә ярдәм итү өчен барлык көч һәм средстволарын бирәләр. Алар 1942 нче елны барлык йөкләмәләрне үтәү өстенә Кызыл Армия фондына 76 центнер ашлык, 40 центнер ит һәм башка күп кенә продуктлар бүләк иттеләр. Танклар колоннасы төзүгә 60.000 сум җыеп бирделәр.

Иптәш Сталинның Татарстан хезмәт ияләренә җибәргән котлау телеграммасына җавап итеп, алар сугыш самолетлары эскадрильясы төзелешенә тагын 75.000 сум акча керттеләр.

Хәзер колхозда язгы чәчүгә кызу әзерлек бара. Бу эш фронт айлыгында тагын да көчәйде. Чәчү орлыклары җитәрлек түгел иде. Колхозчылар орлык әзерләүдә колхозга нык булышлык күрсәттеләр. Алар колхозда җитешми торган орлыкларны үз хуҗалыкларындагы запаслардан бирделәр.

Гүзәл хәрәкәткә киң колач

(Дөбьяз район советы башкарма комитеты председателе иптәш С. Назиров белән беседа).

Район колхозларында чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы уңышлы рәвештә дәвам итә. Айлык башланганнан бирле чәчүгә әзерлек эшләре шактый көчәйде. Бүгенге көнгә колхозчылар колхоз амбарларына 600 центнер бөртекле ашлык, 901 центнер бәрәңге һәм 10 килограмм яшелчә орлыгы салдылар. Районның 20 колхозы, барлык төр культуралар буенча да, чәчү орлыгы белән үзләрен тулысынча тәэмин иттеләр.

«Кызыл байрак» колхозы үзеннән арткан 300 центнер ашлыкны чәчүлек орлыклары җитми торган колхозларга бирергә булды. Мәсәлән, ул «Маяк» колхозына 100 центнер һәм «Марс» колхозына 80 центнер орлык бурычка биреп тора.

Шул ук «Кызыл байрак» колхозы членнары тарафыннан башлап җибәрелгән бер гүзәл инициатива турында әйтеп үтәргә кирәк. Колхозчылар үзләренең гомуми җыелышларында «Перелив» колхозының 100 гектар җирен чәчеп бирергә йөкләмә алдылар. Бу гүзәл хәрәкәт башка колхозларда да киң җәелдерелә. Кызыл байраклылар үрнәгендә «Новая жизнь» колхозы «Авангард» колхозының 90 гектар җирен, «Колос» колхозы «Таң» колхозының 30 гектар җирен чәчеп бирергә булдылар.

Колхозчылар үз хуҗалыкларындагы запас ашлыктан колхозга чәчүлек орлык биреп тору эшенә дә актив катнашалар. «Көрәш» колхозы члены Зәки иптәш Садыйков 3 центнер бәрәңге, 2 центнер бөртекле ашлык һәм «Тамак» колхозы члены иптәш Утяков 2 центнер бәрәңге орлыгы бирделәр.

100 гектарлык орлык бирәләр

КУКМАРА, 16 март. (Телефон буенча). Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы башлану белән «Кызыл купка» колхозы членнары колхозның чәчү орлыгы турында кайгырта башладылар. Алар үз хуҗалыкларындагы запастан колхозга чәчүлек орлык биреп торырга булдылар. Кырчылык бригадирларыннан Сәлахова, Латыйпова һәм ат караучы Шакиров иптәшләр 5 әр пот бөртекле ашлык, Сәрвәр Рәҗәпова 18 пот бәрәңге, Шәйхетдинов бер гектарлык тәмәке орлыгы, бер центнер бәрәңге һәм яшелчә орлыгы бирде.

«Кустарь» һәм Вахитов исемендәге колхоз членнары да бу эштә активлык күрсәтәләр. «Кустарь» колхозы членнарыннан Шакирова 6 пот һәм Ибраһимова 24 пот бөртекле ашлык бирделәр.

Вахитов исемендәге колхоз членнары колхозның 100 гектар җирен үз орлыклары белән чәчеп бирергә йөкләмә алдылар.

Г. ГАЛИЕВ.

ОРЛЫК ӘЗЕРЛӘҮ ӨЗЕКЛЕКТӘ

ТЕЛӘЧЕ, 16 март. (Телефон буенча). «Красный ключ» колхозында чәчүлек орлыклар әзерләү гафу ителмәслек начар тора. Бүгенге көндә колхозның нибары 5 процент кына чәчү орлыгы бар. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау, сбруйларны төзәтү эшләре дә бик акрын бара.

Бирердә, гомумән, язгы чәчүгә әзерлек эшләре турында чынлап кайгыртучы юк. Колхоз председатале Лаврентьев үз эшенә җавапсыз карый. Колхозчыларның артык ашлыкларыннан чәчүлек орлык алып тору буенча ул бернинди дә эш алып бармый. Шулай ук бәрәңге һәм яшелчә орлыклары әзерләү дә оештырылмаган. Хәлбуки, һәр колхозчы хуҗалыктан теләгән кадәр яшелчә орлыгы табарга мөмкин. Чөнки күрше колхозлар бу колхоздан һәр елны яшелчә орлыгы сатып алалар. Димәк, колхозның үзен җитәрлек күләмдә яшелчә орлыгы белән тәэмин итү һич тә кыен эш түгел. Бары тик моны тиешенчә оештыручы кеше генә юк. Шушы көнгә кадәр колхозда нибары 250 грамм чөгендер һәм 150 грамм кыяр орлыгы җыелган.

Язгы чәчүгә әзерлек буенча өзеклектә булган бу колхозга район оешмалары аеруча игътибар итәргә, ә эшлексез председатель Лаврентьевка карата ашыгыч чаралар күрергә тиешләр.

М. МЕДВЕДЕВ.

ЯШЬЛӘРНЕҢ ЧЫН ҖИТӘКЧЕСЕ БУЛЫРГА!

ВЛКСМ НЫҢ VI НЧЫ КАЗАН ШӘҺӘР КОНФЕРЕНЦИЯСЕННӘН

14—15 нче мартта ВЛКСМ ның VI нчы Казан шәһәр конференциясе булып үтте. Конференция комсомолның шәһәр комитетының эше турында отчет тыңлады. Докладны шәһәр комитеты секретаре иптәш Изюмов ясады.

Фикер алышуларда чыгып сөйләгән делегатлар отчет докладын эшлекле рәвештә тикшерделәр һәм шәһәр комитетының эшен кискен рәвештә тәнкыйть иттеләр.

Н-че заводның цех комсоргы иптәш Митин, ВЛКСМ ның шәһәр комитеты комсомолецлар белән аралашмый, оешмаларның тормышын бары тик сводкалар һәм отчетлар буенча гына «өйрәнә», дип күрсәтте.

ВЛКСМ ның Молотов райкомы секретаре иптәш Глушкин райондагы комсомол активының ничек укуы һәм үзенең идея-теоретик белем дәрәҗәсен ничек күтәрүе турында сөйләде. Бу эштә,—диде иптәш Глушкин,—бездә әле бик күп җитешсезлекләр бар. Аерым комсомолецлар гына түгел, хәтта ВЛКСМ комитетларының кайбер секретарьлары да укымыйлар.

Н-че заводның цех комсоргы Сабиров һәм һава көчләре махсус мәктәбенең ВЛКСМ комитеты секретаре Стеценко иптәшләр ВЛКСМ членнарын учетка алудагы буталчыклык һәм комсомол документларын саклауга ялгыш карашлар турында сөйләделәр. Иптәш Стеценко ВЛКСМ ның шәһәр комитеты аппаратының кайбер работникларының политик гамьсезлекләрен күрсәтә торган факт турында сөйләде. Күптән түгел бер группа работниклар (учет бүлеге мөдире Шманянц, эш башкаручы Скоробогатова һ. б. иптәшләр) үзләренең комсомол билетларын бергә җыйганнар да, ВЛКСМ райкомына барып, членлык взнослары түләү өчен ул билетларны учреждение җыештыручы бер кешегә тапшырганнар...

Югары уку йортларындагы комсомол оешмалары секретарьларыннан Костриков һәм Зайдштейн иптәшләр, үзләренең чыгышларында, ВЛКСМ ның шәһәр комитеты югары мәктәпләргә бернинди дә игътибар бирми, студентларның ничек укулары һәм ничек яшәүләре белән кызыксынмый, дип күрсәттеләр.

Н-че заводның ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы иптәш Котова комсомолецларның фронтка ничек ярдәм итүләре турында сөйли. Хәзер бездә,—диде ул,—Кызыл Армия Баш Командованиесенең куәтле фондын төзү буенча социалистик ярыш киң җәелдерелә. Һәрбер комсомолецның үзенең шәхси счеты бар, анда планнан тыш эшләнгән продукция язылып барыла.

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш Луцкер үзенең чыгышында, комсомолның шәһәр оешмасы эшендә әле бик күп җитди кимчелекләр барлыкны күрсәтте. Күп кенә предприятиеләрдә әле эш һаман да «искечә» баруын да дәвам итә. ВЛКСМ комитетларының кайбер секретарьлары һәм кайбер комсорглар производство тормышын тиешенчә өйрәнмиләр, яшьләрнең социалистик ярышына җитәкчелек итмиләр. Иптәш Луцкер союзның эчке эшләрен яхшырту кирәклекне, комсомол җыелышларының әһәмиятен күтәрергә, аларны комсомолецлар һәм яшьләрне политик тәрбияләү мәктәбе итәргә кирәклекне күрсәтте. Беренче Май алды ярышын җәелдерүдә һәм язгы чәчүгә әзерлектә шәһәр комсомол оешмаларының бурычлары турындагы мәсьәләгә иптәш Луцкер аеруча тукталды.

Фикер алышуларда 3 нче номерлы һөнәр училищесының комсомол комитеты секретаре Петров, Н-че заводның ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы Цыряева, Н-че заводның ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы Степанова, ВКП(б) шәһәр комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире Калмыкова һ. б. иптәшләр — барлыгы 23 кеше чыгып сөйләделәр.

Конференция ВЛКСМ ның Шәһәр Комитетының отчет чорындагы эшен канәгатьләнмәслек дип тапты. Кабул ителгән резолюциядә комсомолның шәһәр оешмасының эшен яхшырту өчен конкрет чаралар билгеләнде.

Конференция 43 кешедән ВЛКСМ ның шәһәр комитетының яңа составын һәм 7 кешедән ревизия комиссиясен сайлады.

Конференциядә Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинга гаять зур күтәренкелек белән хат кабул ителде.

* * *

Кичә, яңа состав пленумының беренче утырышы булды. ВЛКСМ ның шәһәр комитеты секретаре итеп иптәш Б. Д. Изюмов сайланды.

ЮГАРЫ ИГЕН УҢЫШЫ ӨЧЕН КӨРӘШ— ДОШМАННЫ ҖИҢҮ ӨЧЕН КӨРӘШ УЛ

КЫЗЫЛ ЮЛ РАЙОНЫ, „ЧУЛПАН“ КОЛХОЗЫНЫҢ ЯЗГЫ ЧӘЧҮ ӨЧЕН ЭШ ПЛАНЫ

* * *

Шушы көннәрдә без үзебезнең Кызыл юл районы, «Чулпан» колхозында язгы чәчү кампаниясенә эш планы төзедек. Башта без үзебезнең әлегә кадәр инде нәрсәләрне эшләп бетергәнлегебезгә йомгаклар ясадык, ә соңыннан киләчәктә үткәрелергә тиеш булган чараларны һәм аларны үткәрү срокларын билгеләдек. Чәчү планын төзегәндә без бары тик үз көчләребезгә генә исәп тоттык.

Яз көне безгә 111 гектар бодай, 147 гектар солы, 37 гектар арпа, 21 гектар ярмалы культуралар (тары һәм карабодай), 70 гектар кузаклы культуралар, 17,5 гектар техник культуралар (җитен һәм киндер), 28 гектар терлек азыгы культуралары һәм 22 гектар бәрәңге чәчәргә кирәк булачак. Ужым культуралары астына 20 гектар тукранбаш чәчелергә тиеш.

Планда күрсәтелгән бөтен мәйданнан 383 гектарын без үз колхозыбызның чәчү әйләнешләрендә һәм 70 гектарын Азин исемендәге күрше артель җирендә чәчәргә тиешбез. Барлык культураларның орлыклары тулысынча әзерләнгән. Алар барысы да сортлылар: бодай—«Лютесценс—062», солы—«Победа», арпа—«Винер», борчак—«Капитал». Планнан тыш чәчү өчен бәрәңге кисентеләре әзерләнә.

БЕЗ КУЛЬТУРАЛАРНЫ НИЧЕК УРНАШТЫРАБЫЗ

Чәчү мәйданнары буенча задание алып, яхшы орлыклар җитештергәннән соң культураларны чәчү әйләнеше кырларына һәм бригадаларның участокларына дөрес урнаштыру бик әһәмиятле. Моннан берничә ел элек без 5 басулы чәчү әйләнешенә күчкән идек. Без быел анда һәрбер культураның чәчү урынын билгеләгәндә, ул җиргә элек нәрсә чәчелгәнен исәпкә алдык. Мәсәлән, аеруча кыйммәтле һәм туфракны бик сайлаучан культура булган бодай үзеннән алдагы елда арыш үскән җиргә чәчеләчәк. Бу җир вакытында һәм яхшы итеп тунга сөрелде. Шуның өстенә без бодайның бер өлешен тукранбаштан бушаган җиргә һәм бер өлешен шуның белән янәшә булган һәм бәрәңге үстереп алынган участокка чәчәчәкбез. Бу җир дә шулай ук тунга сөрелде һәм ашланды.

Тары сызма культуралар кырына, чүп үләннәрдән бик яхшылап чистартылган һәм тунга сөрелгән җиргә чәчеләчәк.

Бригадалар буенча эш ничек тора? Бодай, солы, тары, борчак, җитен, вика кушылмасы һәм бәрәңге кебек культураларны кырчылык бригадалары өчесе дә чәчәчәк, арпаны икенче һәм өченче бригадалар, карабодайны һәм орлыклык виканы өченче бригада гына, ә киндерне беренче бригада гына чәчәчәк.

БРИГАДАЛАРНЫҢ КАРШЫЛАУ ПЛАННАРЫ

Культураларны чәчү әйләнеше басуларына һәм бригадаларның участокларына урнаштырганнан соң без иген уңышы заданиеләрен билгеләргә керештек. Һәрбер бригада буенча заданиене район башкарма комитеты тарафыннан колхозга җиткерелгән иген уңышы планына туры китереп билгеләдек. Безнең бригадалар, бу заданиеләрне алганнан соң, аларны шактый арттырып үтәү һәм иң күп уңыш алу өчен практик чаралар билгеләделәр. Шуның белән бергә аерым кырларның һәм участокларның үзләренә хас сыйфатлары, шулай ук үткән еллардагы тәҗрибә исәпкә алынды. Мәсәлән, икенче бригада бодайны 38 гектар чәчәчәк: шулардан 14 гектары бик яхшылап ашланган һәм тунга сөрелгән, бәрәңге үстереп алынган җиргә, ә 24 гектары арыш җиренә чәчеләчәк. Арыш чәчелгән җирдә туфрак начаррак, ул берничә ел инде ашланмый килгән. 14 гектар җирнең һәр гектарыннан 18 центнер, ә 24 гектар җирнең һәр гектарыннан 16 центнер уңыш алырга билгеләнде. Уртача алганда икенче бригада үзе чәчә торган мәйданның һәр гектарыннан кимендә 16,1 центнер бодай алырга тиеш.

Бу бригада арпаның 7 гектарын тукранбаштан бушаган җиргә һәм 10 гектарын арыш җиренә чәчәчәк. Үткән елларда бездә тукранбаштан соң чәчелгән бу культура гектарыннан 20 центнер уңыш биргән иде. Быел да бригада шундый уңыш алу өчен көрәшә. Ә 10 гектар җирдә ул һәр гектардан 18 центнер алачак.

Арышны икенче бригада иртә пар җиренә 52 гектар һәм чәчүле парга 20 гектар чәчте. Уртача алганда һәр гектардан кимендә 16,7 центнер арыш алырга билгеләнде.

Безнең колхозда бөртекле культураларның уртача уңышы гектарыннан 16,2 центнер, кузаклы культуралар—12,2, ярмалы культуралар—10, орлыклык җитен—3,5, орлыклык киндер—3,5 һәм бәрәңге 125 центнер булырга тиеш.

Шундый уңыш алу өчен күп киң агротехника һәм оештыру чаралары үткәрергә кирәк. Без күп нәрсәләрне эшләдек инде. Бездә, барыннан да элек, ужым культуралары яхшы хәлдә. Алар кар белән бик әйбәт капланган. Яз көне 180 гектар җирдә ужым культуралары чәчүлекләрен тырмалау һәм 15 гектар җирдә тукландыру үткәреләчәк. Барлык кышкы агротехника чаралары планы уңышлы үтәлә. Кар тоту 328 гектар җирдә үткәрелде (план буенча 253 гектар булырга тиеш), басуга 683 тонна тирес чыгарылды (план—800 тонна), 77 центнер көл җыелды (план—100 центнер); 40 центнер кош тизәге җыелды (план—45 центнер), 98 центнер башка төрле җирле ашламалар әзерләнде.

План буенча барлык бодай, солы, арпа һәм тары орлыклары агуланырга тиеш. Бодай, арпа һәм тары бөтенләе белән, солы—чәчү мәйданының ярытысы күләмендә һәм бәрәңге—3 гектарга җитәрлек кадәр яровойлаштырылачак. Арпаның 9 гектарында мульчирование үткәреләчәк.

УНБЕР КӨНДӘ ЧӘЧЕП БЕТЕРӘБЕЗ

Кар китү белән чәчү эшләре башланганчыга кадәр басуларыбызны камылдан һәм чүп үләннәрдән чистартачакбыз. Бу әһәмиятле эшкә без барлык колхозчыларны туплыйбыз.

Без агротехника чараларын киң күләмдә куллануны планлаштырабыз, һәм бу эш эшләнәчәк. Ләкин агротехника чаралары бары тик барлык язгы кыр эшләрен вакытында һәм югары сыйфатлы итеп үкәргәндә генә яхшы нәтиҗәләр бирәчәкләр.

Тиз һәм яхшы чәчү өчен бездә нинди мөмкинлекләр бар? Яз көне безгә тунга сөрелгән 103 гектар җирне эшкәртергә һәм 350 гектар җирне яздан сөрергә кирәк булачак. Бездә туфрак көлсу һәм балчыксыл. Җир чүп үләннәрдән шактый чиста. Ләкин бездә тунга сөрелгән җир яз көне бик нык тыгызлана. Шуңа күрә без 55 гектар җирне культивацияләргә, ә 48 гектар җирне яңадан сөрергә һәм шул ук вакытта тырмаларга уйлыйбыз. Без бу эшләрне, шулай ук сөрү катлавының тулы тирәнлегенә яз сөрүне һәм шул ук вакытта тырмалауны 11 көн эчендә тәмам итәргә уйлыйбыз. Бары тик машиналар белән генә чәчәчәкбез. Иртә культуралар (тарыдан, карабодайдан һәм бәрәңгедән башкаларын) чәчүне 11 көндә үткәрәчәкбез.

План төзегән чакта без академик Т. Д. Лысенконың «Совет авыл хуҗалыгы фәненең якындагы бурычлары» дигән мәкаләсендәге күрсәтмәләрне кулланып эш иттек. Нигездә бу күрсәтмәләр, эшне югары сыйфатлы итеп, чәчүне иң иртә срокларда үткәрүгә кайтып калалар. Шуның белән бергә, чәчүне тизләтү аркасында һич тә җир начар эшкәртелмәскә, басулар чүпләнмәскә һәм туфрак кипмәскә тиеш. Без язгы чәчү эшләренең сыйфатына нык лы контроль куябыз. Моның өчен правление һәм бригадирларга ярдәмгә аеруча тәҗрибәле колхозчыларны сыйфат инспекторлары итеп билгелибез.

Иртә культураларны чәчү өчен безгә түбәндә күрсәтелгәнчә эш куллары һәм тарту көче, шулай ук авыл хуҗалыгы инвентаре кирәк булачак:

Эш төрләре	Эшнең күләме	Үтәү срогы (көннәр)	Бер көнгә задание	Эш нормасы	Кирәк: Кеше	Ат	Инвентарь
1. Ужым культуралары астына тукранбаш чәчү	20 га	1	20	4 га	5	1	—
2. Ужым тырмалау	180 „	2	90	4 „	22	44	22 тырма
3. Ужымны тукландыру	15 „	2	7,5	—	4	1	—
4 Тунга сөрелгән җирне культивацияләү	55 „	2	27,5	4 „	7	14	7 культиватор
5 Тунга сөрелгән җирне яңадан сөрү	48 „	2	24	2 „	12	24	2 төрәнле 12 сабан
6. Тунга сөрелгән җирне ике эздән тырмалау	103 „	2	52	4 „	13	26	13 тырма
7. Язгы сөрү	350,48 „	9	35	1,75	20	40	20 сабан
8. Яз сөрелгән җирне ике эздән тырмалау	350,48 „	9	35	4 „	9	18	9 тырма
9. Иртә культуралар чәчү	411 „	11	38	1 сошникка 0,8 га	8	12	4 чәчү машинасы (атлар алмашлап эшли)
10 Орлык ташу	649 цент.	11	60	15 цент.	4	2	—

Бездә бригадаларга беркетелгән, хезмәткә яраклы колхозчылар 79 кеше. Колхозның 48 эш аты һәм 13 баш 3 яшьлек атлары бар. Алар барысы да кыр эшләрендә эшләячәкләр. Атлар һәм аларга билгеләнгән җигү әйберләре бригадаларга, ә бригадалар эчендә ат карауучыларга һәм ат йөртүчеләргә беркетелгән. Правление һәм бригадирлар атларны тәрбияләүне системалы рәвештә тикшереп торалар, алардан файдалануны оештыралар. Хәзер атлар, бөтенләй диярлек концентратлар алмауга да карамастан, аларның күп өлеше яхшы хәлдә.

БАРЛЫК РЕЗЕРВЛАРНЫ ҺӘМ МӨМКИНЛЕКЛӘРНЕ ФАЙДАЛАНЫРБЫЗ

Барлык чәчү эшләрен билгеләнгән срокларда үтәү өчен бездә 15 ләп ат җитеп бетми. Бу кимчелекне без эчке мөмкинлекләр исәбенә бетерәчәкбез.

Барыннан да элек, көзге культуралар җиренең бер өлешен кул белән тырмаларга уйлыйбыз. Илебезнең көнбатыш өлкәләрендәге колхозлардан үрнәк алып, без моның өчен кул тырмалары әзерли башладык. Һәрбер 5 кеше бер көн эчендә бер гектар җир тырмалаячак. Бездә кешеләр җитәрлек. Алар югары уңыш алу өчен бөтенесен эшләргә әзер торалар. Кар эри башлау белән үк без җирләрнең кардан арчылуын җентекләп күзәтеп торачакбыз.

Язгы кыр эшләрен, бөтен җир өлгереп җиткәнне көтеп тормыйча, аерым җир участокларында туфрак өлгерә барган саен сайлап алып үткәрә башлаячакбыз.

Безнең авылдан 2,5 километр ераклыктагы участокта кыр станы төзергә уйлыйбыз. Ул чәчү вакытында атларны ял иттерүне яхшы итеп оештырырга һәм эшләп чыгарышны арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк. Нәтиҗәдә кыр эшләренең сроклары да кыскарачак.

Атларга ярдәмгә без авыл хуҗалыгы эшләрен башкару өчен 16 баш мөгезле эре терлекне әзерлибез. Моның өчен колхозчылар үзләренең 12 сыерларын бирәләр. Алар өчен җигү әйберләрен колхоз правлениесе әзерли.

Колхозда авыл хуҗалыгы инвентаре җитәрлек. Аларның барысына да ремонт ясалган һәм алар сарайда сакланалар. 43 данә сука камыты әзерләнеп куелды. Шорник Заһидулла Батыршин аларны тагын да әзерли. 48 данә җигү камыты бар, 25 арбага ремонт ясалды, валеклар, постромкалар, дилбегәләр һәм башка төрле җигү әйберләре әзерләнде, күпчәк мае сатып алынды. Капчыклар да җитәрлек.

Без план төзүгә эш нормаларын яңадан карап чыгу белән керештек. 2 төрәнле сабанга эш нормасы тунга сөрелгән җирне яңадан сөрүдә 2 гектар һәм язгы сөрүдә 1,75 гектар итеп алынды. Үзебездә эшләнгән культиваторга 4 гектар, ике буынлы тырмага, 2 ат җигеп ике эздән тырмалаганда 4 гектар, чәчү машинасына бер сошникка 0,8 гектар норма кабул иттек. Нормалар тикшерелгән чакта колхозчылар безнең иң яхшы стахановчыларыбызны үрнәк итеп китерделәр. Менә фронтовик Габделхак Җаппаров. Үткән елны ул ике төрәнле сабан белән көненә 2,4 гектар сөрде. Сәмигулла Галиев бер сошникка берәр гектар һәм аннан да күбрәк чәчте. Карт Сәлах Шәрәфиев 2,5 гектарга кадәр сөрде, Асия Сибгатуллина 11 рәтле чәчү машинасы белән 12 шәр гектар чәчте.

ҺӘРБЕР КОЛХОЗЧЫ ҮЗЕНЕҢ ЭШ УРЫНЫН БЕЛӘ

Планда билгеләнгән барлык культуралар буенча иң яхшы җирләрдә орлыклык участоклар аерып куйдык. Мәсәлән; орлыклык бодайны (бөтен бодай җиренә карата 15 процент, ягъни 16,6 гектар) беренче бригадага беркетелгән җиргә чәчәчәкбез. Үткән елны анда эшләнгән пар җиренә арыш чәчелгән иде. Җир яхшы, тунга сөрелгән. Шул ук беренче бригада җирләрендә орлыклык солы, киндер, арыш һәм тукранбаш участоклары да аерып куелды. Икенче бригада орлыклык арпа, тары, борчак, җитен һәм бәрәңге, ә өченче бригада орлыклык карабодай һәм вика чәчәчәк.

Һәрбер бригадада орлыклык участоклар аерым звеноларга беркетелгән. Мәсәлән, икенче бригадада үзенә билгеләнгән барлык культуралар буенча орлыкларны Шакир Әхмәтҗанов звеносы, беренче бригадада Харис Хәсәнов звеносы, өченче бригадада Төхфәт Фазуллин звеносы җитештерәчәк. Бу звенолар орлыклык участоклар өчен билгеләнгән җирләрдә кар тоталар, бу җирләр өчен ашламалар әзерлиләр. Бу җирләр өчен булган чәчүлек орлыклар тагын бер кат триердан үткәреләчәк, ә кузаклы культуралар змейка аркылы үткәреләчәк кулдан сайланачак. Бодай һәм арпа термик юл белән агуланачак.

Бездә язгы чәчүгә эш планнары һәрбер кырчылык бригадасы өчен төзелгән. Барлык бригадалар 7—9 кешелек звеноларга бүленгәннәр. Аларга орлыклык участоклар, шулай ук тары, җитен, киндер һәм бәрәңге җирләре беркетелгән. Бөртекле һәм кузаклы культуралар, орлыклык участокта булмасалар, звеноларга беркетелмиләр, тоташ көенә бригада карамагында калалар.

Кыр эшләре башланырга күп вакыт калмады. Аларга безнең колхоз нигездә әзер. Без эчке тәртип кагыйдәләре төзедек. Кешеләр чәчү вакытында кем, кайда һәм нәрсә эшләргә тиешлекне беләләр. Мәсәлән, икенче бригаданы алыйк. Анда җир сөрү эшендә Шакир Әхмәтҗанов, Борһан Габдрахманов, Ярулла Хәбибуллин, Мәсгут Шәйхиев, Мансур Бариевлар, чәчү эшендә Асия Биктова һәм Садыйк Вильдановлар, тырмалауда Нәгыймә Хөснетдинова һәм Хәбри Абдуллиналар эшләячәк. Хәзер сөрүчеләр, чәчүчеләр, тырмалаучылар һәм башка күп колхозчылар агротехника түгәрәгендә укыйлар. Түгәрәккә Фәхри Галиева җитәкчелек итә. Колхозчылар агротехниканы яхшы үзләштерү өчен үзара ярышалар, көн саен тырышып эшләргә, нормаларны үтәргә һәм арттырып үтәргә сүз бирәләр. Безнең колхоз кешеләре быел барлык культуралардан югары уңыш алу өчен, илебезгә һәм фронтка авыл хуҗалыгы продуктларын мөмкин кадәр күбрәк бирү өчен бөтенесен эшләрләр.

Колхоз председателе **А. БИКТОВ.**

Бригадирлар: **Ф. ГАЛИЕВА Г. ФӘЙЗИЕВ, М. ГАЛӘВЕТДИНОВА.**

Хисапчы **Ф. ГАЛИЕВ.**

Азат ителгән Ростовта. Рәсемдә: Энгельс урамы күренеше. Совет кешеләре үзләренең квартираларына кайталар.

ТАСС фотохроникасы.

Совет Информбюросыннан

16 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

лициянең котырынган цензурасына да карамастан, безгә немецлар каторгасына өләккән авылдашларыбызның җанны әрнетә торган кызганыч хатлары килә иде. Фашистлар пленлыгыннан алар: —Бераз гына булса да продуктлар җибәрегез, безне монда ачлыктан үтерәләр—дип язалар иде.

Чигенер алдыннан немец солдатлары командасы безнең авылны яндырды. 43 йорттан 36 йорт барлык каралтылары һәм колхозчыларның милекләре белән берлектә янып бетте. Немецлар авылның бөтен халкын үзләре белән алып китәргә маташтылар. Кызыл Армиянең тизлек белән алга баруы гитлерчылар арасында буталыш тудырды. Колхозчылар, немецларның каушап һәм аптырап калуларыннан файдаланып, фашистлар коллыгыннан котылдылар.

Немецлар безнең якта озак башбаштакланып йөрделәр һәм совет гражданнарын мыскылладылар. Фашист басып алучылар китерә торган «яңа тәртип»нең нәрсә икәнлеген без үз җилкәбездә татыдык. Кеше ашаучы гитлерчылар эшләгән җинаятьләрне без гомердә дә онытмабыз. Үлем һәм мәңгелек ләгънәт аларга!». Җелудки авылы крестьяннарының гомуми җыелышының тапшыруы буенча актка кул куйдылар: Матвей Жуляев, Ульяна Максимова, Евдокия Ванина.

ЮГОСЛАВИЯ ПАРТИЗАННАРЫНЫҢ КӨРӘШЕ

ЖЕНЕВА, 15 март. (ТАСС). Югославиядән алынган хәбәрләргә караганда, партизаннар итальян-немец һәм усташи гаскәрләренә каршы бик каты сугышларны дәвам иттерәләр.

Неретва елгасы һәм Сараево—Мостар тимер юлы буенда зур сугышлар башланып киткән. Партизаннар, елганың сул як ярына чыгып, Коница шәһәре янындагы таулык районда урнашкан усташи частьларына каршы һөҗүм башлаганнар. Шул тирәдә булган сугышларда партизаннар дошманның 120 солдат һәм офицерын юк иткәннәр һәм 40 солдат һәм офицерны плен алганнар. Мостар шәһәре янында дошманның бер тимер юл станциясендә урнашкан колоннасы тар-мар ителгән. Партизаннар бик күп корал, азык складны һәм әһәмиятле документлар кулга төшергәннәр.

Словениядә дә шулай ук сугышлар дәвам итә. Камник һәм Моровец дигән халык яши торган пунктлар янында барган сугышлар вакытында партизаннарның 2 отряды немецларның 400 солдат һәм офицерын кырып ташлаганнар һәм шактый күп санда сугыш материалларын кулга төшергәннәр. Партизаннар, кинәт һөҗүм ясап, халык яши торган Градац һәм Отрич пунктларын алганнар һәм дошманның 2 төзек танкысын һәм бик күп автомат коралларын кулга төшергәннәр.

Вашингтондагы матбугат конференциясендә Иденның белдерүе

ВАШИНГТОН, 13 март. (ТАСС). Бөек Британиянең чит ил эшләре министры Иден, матбугат конференциясендә чыгыш ясаган вакытта, җиңүгә ирешкәнгә кадәр алда әле авыр көрәш тора, дип белдерде. Сугышта җиңеп чыкканга кадәр күп кенә җиңелүләрне һәм күңел кайтуларны кичерергә туры киләчәк. Иден, Кушма Штатлар белән Советлар Союзы арасындагы мөнасәбәтләр ныклы нигезгә куела алачак, дип ышаныч белдерде. Аннары ул: «Кызыл Армиянең уңышлары һәм бөтен кыш буена русларның җиңүләре искиткеч зур булды», — дип әйтте. Иден декабрь аенда түбәнге палатада ясаган белдерүендә АКШ, Бөек Британия һәм Советлар Союзы арасында хезмәттәшлекнең кирәк икәнлеген күрсәткән иде. Бу белдерүне тагын да ачыкландыра төшүне сорагач, Иден: «Минем фикеремчә, мондый хезмәттәшлек тынычлык өчен кирәкле һәм ныклы нигез булып тора»,—дип белдерде. Шулай ук Кытай белән һәм башка берләшкән милләтләр белән хезмәттәшлекне тәэмин итәргә кирәк. «Саклык чараларын күрү гаять әһәмиятле. Монысында Германиянең һәм Японияның агрессияне һичкайчан яңадан тормышка ашырмауларын тәэмин итәргә кирәк».

Сугыштан соң Германиягә һәм Италиягә билгесез срокка кадәр контроль урнаштыруны кирәк дип саныйсызмы; дигән сорауга Иден болай дип җавап бирде: «Үткән сугыштан соң без торган позициядә яңадан торырга ярамый. Минем фикеремчә, киләчәктә, саклык чараларын күрмичә торып, Германиядә яңа хөкүмәт төзү генә җитми». Газета хәбәрчеләре Иденнан, сезнең Вашингтонга килүегез Англия—Совет арасында 20 елга төзелгән договорга кагылмыймы, дип сорадылар. Иден аларга: «Мин, Англия һәм Советлар Союзы үзләренең ике арадагы мөнасәбәтләрен ныклы ышаныч базасына корырга тиешләр, дип санап килдем. Бу договор белән шушындый ышанычка ирешелде»,—дип җавап бирде. Иден бу договорга кул куелу СССР белән Англия арасындагы мөнасәбәтләрдә «тарихи борылыш» икәнлеге турында Сталинның белдерүен күрсәтеп үтте. Аннары Иден болай диде: «Атлантика хартиясе һәм берләшкән милләтләрнең декларациясе бу договорга нигез итеп куелды һәм ул сугыштан соң ышанычны саклауны тәэмин итәчәк». Иден Совет—Польша чикләре турындагы мәсьәләгә аңлатма бирүдән баш тартты.

Иден Кушма Штатларда күпме вакыт торачагын белмәгәнлеген һәм АКШ та эшләрен тәмам иткәннән соң, Канадага барырга теләгәнлеген белдерде. Михайлович белән партизаннар арасындагы фикер башкалыклары мәсьәләсенә кагылып, Иден, бу фикер башкалыклары Югославия дәүләтендә серблар, хорватлар һәм словеннар арасында яшәп килгән үзара мөнасәбәтләрне беркадәр чагылдыралар, дип күрсәтте һәм бу проблеманың хәл ителәчәгенә ышаныч белдерде. Иденның әйтүенә караганда, Финляндиянең сугыштан чыгарга теләгәнлеге турында аңа хәбәрләр алынмаган. Аннары ул болай диде: «Бөек Британия хөкүмәте Германиягә каршы көрәштә барлык французларның берләшүен тели. Мондый бердәмлеккә ирешү өчен беркадәр вакыт кирәк булуы мөмкин. Англия сугыштан соң Франциянең көчле булып төзелүен тели». Үзенең нинди максат белән килүе турындагы мәсьәләгә кагылып, Иден, коммюникеда күрсәтелгәнчә; «минем килүемнән максат хәрби хәлнең барлык яклары турында гомуми фикер алышудан гыйбарәт», дип күрсәтте. Иден күп кенә кешеләр белән очрашырга, шулай ук Америка армиясе һәм флоты частьларына, шулай ук хәрби предприятиеләргә барырга тели. Сугыштан соңгы авиация проблемалары турында киңәшергә телисезме, дигән сорауга Иден болай дип җавап биреп: «Минем фикеремчә, бу мәсьәләгә һава юлларын милләтләрнең тагын да якынаюлары средстволарына әйләндерү ягыннан якын килергә, бу өлкәдә көндәшлек ягыннан чыгып эш итмәскә кирәк»,—диде һәм бу проблеманы яхшы итеп хәл итүгә ирешеләчәгенә ышаныч белдерде. Аның әйтүенчә, хәзерге вакытта Германиядәге эчке вакыйгаларга бәя бирү кыен, ләкин шунысы ачык ки, Германия сугыштан чыгудан ерак тора әле. Сугыштан соң Италиянең хәленә кагылып, Иден түбәндәгеләрне әйтте: «Минем фикеремчә, Италия озак вакытларга кадәр безгә куркыныч тудыра алмаячак». Аннары Иден, союзниклар үзләренең куәтләрен сизә башлаган һәм бу куәтне дошманнар да сизгән бер вакытта АКШ ка килгәнлеген әйтеп үтте һәм түбәндәге лозунг буенча эшләргә кирәклеген белдерде: «Эш өчен алга! Алда авыр эш тора, ләкин берләшкән милләтләр гомуми тырышлыклар, белән аны үти алачаклар».

СОЮЗНИКЛАР АВИАЦИЯСЕНЕҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 15 март. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенә караганда, кичә «Уирлуинд» бомбардировщиклары дошманның Франциядәге аэродромнарына һөҗүм ясаганнар.

Американың авыр бомбардировщиклары 14 нче мартка каршы төндә Неаполь гаванена һөҗүм иткәннәр.

Англия авиациясе 15 нче мартка каршы төндә Германиядә һәм оккупацияләнгән илләрдә дошманның коммуникацияләренә һөҗүм ясаган, 4 тимер юл составы бомбага тотылган.

Дошман самолетлары Эссекс графлыгындагы ике пунктка бомбалар ташлаганнар. Берничә кеше үлгән.

ЖЕНЕВА, 15 март. (ТАСС). Эссенда гитлерчылар тарафыннан чыгарыла торган «Националь цейтунг» газетасы, 13 нче мартка каршы төндә Англия авиациясенең һөҗүме нәтиҗәсендә, шәһәрдә бөтенләй тәртипсезлек хөкем сөрә, дип икърар итә. Властьлар Эссен шәһәрендә хәрби халәт игълан иткәннәр. Җимерелүләр шул кадәр зур ки, кемгә булса да тиз ярдәм күрсәтү мөмкин түгел. Һөҗүмнән зарарланучылар өчен торак урыннар җитми. Халыкка бомбадан саклану урыннарына үзләренең әйберләрен алып бару тыелган, чөнки аларда урын юк.

Чит ил хроникасы

—АКШ та су асты көймәләренә каршы көрәшү өчен разведка алып бара торган кечкенә дирижабльләрдән киң күләмдә файдалана башлаганнар. Кай вакытларда алар яр буйларыннан 3 мең миль ераклыкка очып разведка алып баралар. Күптән түгел АКШ конгрессы шушындый 200 дирижабль төзү планын раслаган. Аларның бер өлеше сугышларда катнаша башлаган.

—Лаваль Франция студентларын Германиягә мәҗбүри эшләргә җибәрү өчен, якын көннәрдә Франциянең барлык университетларын ябарга теләгәнлеген белдергән.

—Флорида штатында (АКШ) банк компаниясенең башлыгы Джон Пирпонт Морган үлгән. (ТАСС).

19 нчы март, 15 сәгатьтә СССР Фәннәр академиясенең гомуми һәм аорганик институты китапханәсендә (Чернышевский урамы, 18 нче йорт, химия корпусы, 2 нче этаж) институт гыйльми советының ачык утырышы була. Утырышта П. П. Солодовников химия Фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен

ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАЯЧАК

Тема: „Висмутка анализ ясаганда гексаметилентетраминны куллану". Рәсми оппонентлар: химия фәннәре докторы, профессор И. В. Тананаев һәм химия фәннәре докторы, проф. Н. К. Пшеницын. Диссертация материаллары белән институт китапханәсендә танышырга мөмкин.

ТАССР Совнаркомы янындагы Җирле ягулык промышленносте идарәсе дәүләт оешмаларына һәм аерым кешеләргә

ТОРФ САТА

Торфны түбәндәге участоклардан алырга мөмкин: 1. Кизица участогы (9 нчы трамвай, Кизица янында туктала торган урын). 2. Борисоглебское участогы (Борисоглебское авылы, 9 нчы трамвай туктала торган урыннан 5 километр). Бер тонна торф 2,8 кубометр касн утыны урынына тора. Торф участогында 1 тонна торфның бәясе 23 сум 35 тиен. Заявка бирү өчен адрес: Университет урамы, 6-нчы йорт, 3 нче этаж, Таттопснабсбыт.

Татарстанда

Спорт яңалыклары

◇Узган якшәмбе көнне «Динамо» ның чаңгы базасында һөнәр училищеларында һәм ФЗӨ мәктәпләрендә укучыларның чаңгы ярышлары булып үтте. Ярышларда 3 нче номерлы һөнәр училищесы беренче урынны яулап алды. Кызлардан чаңгыда беренче номерлы һөнәр училищесында укучы Голубева, 2 километр араны 12 минут 30 секундта, малайлардан шул ук һөнәр училищесында укучы Минов, 3 километр араны 16 минут 30 секундта үтеп, 1 нче урынга чыктылар.

◇Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә үткәрелгән профсоюз-комсомол чаңгы кроссында Татарстанда барлыгы 119.788 кеше, шул исәптән Казан шәһәрендә 37.056 кеше катнашты. Шулардан 94.610 кеше ГТО га һәм БГТО га норма тапшырдылар.

◇Балаларның спорт мәктәбе Кызыл Армия йортында бокс буенча ярышлар үткәрде. Ярышлар нәтиҗәсендә укучылардан 19 кеше 4 нче разряд боксер һәм 3 кеше 3 нче разряд боксер исемен алдылар. Хәзер Казан шәһәренең боксерлары шәһәр беренчелеге өчен ярышларга әзерләнәләр.

◇Татарстанда иң көчле шахматчыларның ярышлары булып үтте. Шахмат турлары хәрби частьларда һәм башка урыннарда алып барылды. Шахматчылардан Казан чемпионы Саигин беренче урынны, беренче категория шахматчылардан Колчурин икенче урынны яулап алдылар.

СУГЫШ ИНВАЛИДЛАРЫНЫҢ РАЙОН КИҢӘШМӘСЕ

Шушы көннәрдә Ютазы район социаль-тәэминат бүлеге ватан сугышы инвалидларының район киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә халыкара хәл турында һәм сугыш инвалидларының материаль-көнкүреш шартларын яхшырту турында доклад тыңланды.

Киңәшмәгә катнашучылар ватан сугышы инвалидларының культура-көнкүреш шартларын яхшырту буенча күп кенә кимчелекләр барлыгын әйттеләр һәм сугыш инвалидларын яңа төр профессияләргә өйрәтү буенча төрле курслар ачарга кирәклеге турында эшлекле тәкъдимнәр керттеләр.

СУД

ЗАКОН БОЗУЧЫЛАР

Шушы көннәрдә ТАССР Верховный Судында, продукт карточкаларын бозып ясау юлы белән җинаять эшләгән бер группаның эше каралды.

Бу группада катнашкан Н. А. Яковлев, Т. И. Мотев, К. Ю. Шалтупер һәм Д. А. Донкарев дигән кешеләр, соңгы берничә ай эчендә икмәк, продукт һәм промтовар карточкаларының номерларын бозып ясап, магазиннардан берничә йөз килограмм икмәк, төрле азык продуктлары, 10 пар киез итек һәм башка әйберләр алганнар, шулай ук ашханә өчен ялган талоннар ясап файдаланганнар.

Судта ачылган фактлардан һәм шаһитларның күрсәтүләреннән аларның җинаятьләре ачык мәгълүм булды. Яковлев, Донкарев 5 әр елга; Шалтупер 3 елга ирекләреннән мәхрүм ителүгә хөкем ителделәр.

Җаваплы редактор И. УЗБЕКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген — «Травиата».

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 18 нче мартта — «Хуҗа Насретдин».

Зур драма театры. Бүген һәм 18 нче мартта — «Фронт».

Яшь тамашачылар театры. Бүген һәм 18 нче мартта кичке 7 сәгатьтә спектакаль—«Кыйнадык, кыйныйбыз һәм кыйнарбыз».

«Электро». Көндез — «Кино-концерт», кич — «Җиңелмәслекләр». «Унион». Көндез — «Багдан Хмельницкий», кич—«Иран» «Пионер». Көндез—«Вулкандагы вакыйга», кич — «Минем мәхәббәтем». «Чаткы». «Таҗикстан улы».

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 1081 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 244